КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2025 ел, 12 сентябрь г.Казань № 6-2056

Татарстан Республикасында массакүләм физкультура-савыктыру хәрәкәтен популярлаштыру, халыкны актив ял итүгә, физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү максатларында:

1. 2025 елның 20 сентябрендә Татарстан Республикасында «Татарстан кроссы – 2025» республика массакүләм ярышларын уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына:

2025 елның 20 сентябрендә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән берлектә, халыкның төрле яшьтәге катламнарын катнашуга массакүләм җәлеп итеп, «Милләт кроссы» бөтенроссия йөгерү көнен әзерләү һәм уздыру эшен оештырырга;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары белән берлектә, халыкның төрле яшьтәге катламнарын анда катнашуга массакүләм җәлеп итеп, «Татарстан кроссы – 2025» республика массакүләм ярышларын үткәрүне оештырырга.

3. Дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының төрле милек рәвешләрендәге предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә әлеге ярышларда үз хезмәткәрләренең катнашуын оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына әлеге ярышларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

5. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына әлеге ярышлар үткәрелә торган урыннарда хокук тәртибен саклауны һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин